Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Рус Акташы авыл Советы
КАРАРЫ

«11» декабря 2020 ел №9

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл Советының 2020 елның 3 мартындагы«Әлмәт муниципаль районы авыл җирлегененңпенсиягә чыгу уңаеннан муниципаль хезмәткәргә тиешле еллар эшләгән өчен бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү тәртибе һәм күләмнәре турында Нигезләмә турында» 141 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 13 ноябрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, хокукый мониторинг тәртибендә

Рус Акташы авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл Советының 2020 елның 3 мартындагы «Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл җирлегенең пенсиягә чыгу уңаеннан муниципаль хезмәткәргә тиешле еллар эшләгән өчен бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү тәртибе һәм күләмнәре турында Нигезләмә турында» 141 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарга кушымтаны 6.1. пункты белән тулыландырырга:

«6.1. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән затка Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булмаганда башкарыла.

Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү сорап мөрәҗәгать иткән көннән соң 90 көн эчендә җайга салынганда, тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу сәбәпле, бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү шундый түләү сорап мөрәҗәгать иткән көннән башкарыла.».

2. Әлеге карарны Рус Акташы авылы, Төзүчеләр урамы, 14 нче йорт; Комсомол урамы, 12б йорты территориясендә; Акташ станциясе контора бинасында урнашкан махсус стендларда игълан итәргә; «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2021 елның 1 январеннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Рус Акташы авыл җирлеге Башлыгына йөкләргә.

Рус Акташы
авыл җирлеге Башлыгы С.А.Белоногов